**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1119**
**04.03.2022**

Башкарма комитетның «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәрендә хезмәтне саклау һәм аның шартларын яхшырту» муниципаль программасын раслау турында» 2019 елның 21 октябрендәге 5365 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмә, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2020-2022 елларга хезмәтне саклау һәм аның шартларын яхшырту» муниципаль программасын раслау турында» 2019 елның 21 октябрендәге 5365 номерлы карарына (Башкарма комитетның 2021 елның 20 февралендәге 1207 номерлы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән программаны тормышка ашыру буенча чараларны финанслауны Яр Чаллы шәһәре бюджетында «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» 01.13 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына тәэмин итәргә, 2020 ел – 32,84 мең сум, 2021 ел – 47,81 мең сум, 2022 ел – 40,0 мең сум.»;

2) «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәрендә хезмәтне саклау һәм аның шартларын яхшырту» муниципаль программасында:

- 1 бүлектә « Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2020 | 2021 | 2022 | Тормышка ашыру чорында барлыгы |
| | Муниципаль бюджет | 32,84 | 47,81 | 40,0 | 120,65 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Федераль бюджет | - | - | - | - |
| | Республика бюджеты | - | - | - | - |
| | Башка чыганаклар | - | - | - | - |
| | Барлыгы | 32,84 | 47,81 | 40,0 | 120,65»; |

- 5 бүлекне кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә;
- 6 бүлекне түбәндәге яңа редакциядә бәян итәргә:

«6 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

2020-2022 елларга программаны финанслау күләме 120,65 мең сум тәшкил итә, шул исәптән программаны тормышка ашыру еллары буенча: 2020 ел – 32,84 мең сум, 2021 ел – 47,81 мең сум, 2022 ел – 40,0 мең сум.

Программаны финанслау чыганагы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты тора.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге башлыгы Р.М. Мингалиевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 4 мартындагы
1119 номерлы карарына
кушымта

5 бүлек. Программаның максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чараларын финанслау

| № т/б | Программа чараларының исеме | Программа чараларын башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Шул исәптән сроклар буенча (мең сум) | | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп, финанслау (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2019 (база) | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел |
| Максат : шәһәр оешмаларында хезмәтне саклау һәм аның шартларын яхшырту | | | | | | | | | | | |
| | Программа нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары | | | Бәхетсезлек очракларының саны, берәмлек | 43 | 42 | 41 | 40 | | | |
| 1 бурыч. Производство травматизмы, беренче чиратта авыр һәм үлемгә китергән травматизм дәрәҗәсен киметү | | | | | | | | | | | |
| 1. | Хезмәтне саклау буенча Координация советлары утырышларын үткәрү | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | 2020-2022 еллар | Үткәрелгән утырышлар саны, берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 | финанслау таләп ителми | | |
| 2. | Квартал саен хезмәтне саклау һәм аның шартларының торышы турында доклад һәм производство травматизмы буенча анализ әзерләү | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | 2020-2022 еллар | Докладлар саны, берәмлек | 4 | 4 | 4 | 4 | финанслау таләп ителми | | |
| 3. | Шәһәрнең ведомство буйсынуындагы белем бирү оешмаларында хезмәтне саклау торышы буенча тикшерү үткәрү | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге, Башкарма | 2020-2022 еллар | Үткәрелгән тикшерүләр саны, берәмлек | 20 | 20 | 20 | 20 | финанслау таләп ителми | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | комитетның мәгариф идарәсе | | | | | | | | | |
| 4. | Физик культура һәм спорт идарәсенең ведомство буйсынуындагы учреждениеләрендә хезмәтне саклау торышы буенча тикшерү үткәрү | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | 2020-2022 еллар | Үткәрелгән тикшерүләр саны, берәмлек | 17 | 17 | 17 | 17 | финанслау таләп ителми | | |
| 2 бурыч. Хезмәткәрләргә хезмәт эшчәнлеге процессында сәламәт һәм куркынычсыз хезмәт шартлары тудыру | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | Муниципаль бюджет | | |
| 5. | Шәһәр оешмалары арасында хезмәтне саклау һәм аның шартлары буенча эшләрне иң яхшы оештыруга шәһәр смотр-конкурсы үткәрү | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | 2020-2022 еллар | Конкурста катнашкан предприятиеләр саны, берәмлек | 65 | 67 | 69 | 71 | 25,54 | 28,61 | 30,0 |
| 6. | Хезмәтне саклау буенча буклетлар, плакатлар эшләү, әзерләү һәм белешмәлекләр тарату | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | 2020-2022 еллар | Әзерләнгән материаллар саны, данә | 150 | 150 | 150 | 150 | 6,3 | 8,2 | 8,0 |
| 7. | Алга таба шәһәр учреждениеләрендә тарату өчен хезмәтне саклау буенча басма белешмәлекләр әзерләү | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | 2020-2022 еллар | Әзерләнгән материаллар саны, данә | 150 | 150 | 150 | 150 | 1,0 | 1,0 | 2,0 |
| 8. | Шәһәр оешмалары арасында хезмәтне саклау һәм аның шартларын яхшыртуны иң яхшы оештыруга шәһәр смотр-конкурсында җиңүчеләрне бүләкләү өчен букетлар | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | 2020-2022 еллар | Әзерләнгән материаллар саны, данә | 10 | 10 | 10 | 10 | - | 10,0 | - |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 9. | Бөтендөнья хезмәтне саклау көненә багышланган чара үткәрү | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге | Ел саен | Үткәрелгән киңәшмәләр саны, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | финанслау таләп ителми | | |
| 10. | Оешмаларда хезмәтне саклау һәм аның шартларының торышы турында шәһәр халкына хәбәр җиткерү | Башкарма комитетның халык иминлеген тәэмин итү бүлеге, Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә идарәсе | 2020-2022 еллар | Бастырып чыгарылган мәкаләләр саны | 4 | 4 | 4 | 4 | финанслау таләп ителми | | |
| | | | | | | | | барлыгы: | 32,84 | 47,81 | 40,0 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева